**I. Укыту предметын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре.**

**Сыйныф**: 4 “А”
**Уку планы буенча татар теленнән**:
**Атнага**: 2 сәг.
Барлыгы - 70 сәг.

**Программа түбәндәге документлар нигезендә төзелде:**

1. Программа: Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы. Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту программасы (1 — 11 нче сыйныфлар). Төзүче – авторлары: Р.З. Хәйдәрова, Р. Л. Малафеева, Әхмәтҗанова, 2017 ел.

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе”нең төп гомуми белем бирү баскычында башлангыч гомуми белем бирү программасы.

3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем мәктәбе”нең 2018-2019 уку елына укыту планы (№__ педсовет протоколы,
__________ 2018 ел).

**Дәреслек**. Күңелле татар теле. Рус телендә башлангыч гомуми белем бирү оешмаларының 4 нче сыйныфы өчен дәреслек (татар телен өйрәнүче укучылар өчен) Төзүчеләре:Р.З. Хәйдәрова, Г.М. Әхмәтҗанова, Л.Ә.Гыйниятуллина Татар теле китабы. Ике кисәктән тора. Казан. «Татармультфильм» нәшрияты, 2014 ел

**Татар теле буенча планлаштырылган нәтиҗәләр**

Планлаштырылган нәтиҗәләр

“Татар теле һәм әдәби уку” предметы буенча 4 нче сыйныф программасын үзләштерүнең шәхси нәтиҗәләре:

– татар теленең дәүләт теле буларак ролен аңлау;

– шәхесара һәм мәдәниара аралашуда татар телен куллануга уңай караш булдыру;

– татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге формалаштыру.

--Әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау.

Татар теленә өйрәтүнең метапредмет (регулятив, коммуникатив, танып-белү) нәтиҗәләре:

– укытучының күрсәтмәләрен аңлап үти белү;
– эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра белү;
– дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли белү, алар белән дөрес эш итә белү;
– дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү;
– әңгәмәдәшең белән аралаша белү күнекмәләрен формалаштыру;
– парларда һәм күмәк эшли белү;
– әңгәмәдәшең белән контактны башлый, дәвам итә, тәмамлый белү;
– үрнәк буенча эшли белү;
– аерым темаларга караган сорауларга җавап бирә белү;
– рәсем буенча җөмләләр, сораулар төзи белү;
– аңлап укый белү;

– укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирү
- чагыштырып нәтиҗә ясый белү күнекмәләрен формалаштыру

Татар теленә өйрәтүнең предмет нәтиҗәләре.

1.Сөйләшу
Диалогик сөйләм. 4 нче сыйныфта дәрес вакытының 60-70%ын сөйләшүгә өйрәнү ала. Сөйләм эшчәнлегенең бу төре буенча укучылар түбәндәге күнекмәләргә ия булырга тиешләр:
- сайланган эчтәлек аша әңгәмәдәшең белән контакт урнаштыра, сорау куя, җавап бирә, кире кага, раслый белү;
- дәреслектә бирелгән үрнәк диалогларны сәнгатьле итеп уку, сөйләү һәм охшаш диалоглар төзү, программада күрсәтелгән коммуникатив максатлар буенча әңгәмәдә катнаша алу.
Монологик сөйләм. Сөйләм эшчәнлегенең бу төре буенча укучылар түбәндәге күнекмәләргә ия булырга тиешләр:
- җанлы һәм җансыз предметларны, рәсем, картина эчтәлеклеген сүрәтләп сөйли белү;
- программада күрсәтелгән темалар буенча кечкенә информация бирә белү.

2.Ишетеп аңлау (аудирование)
Аралашу өчен төп шартларның берсе – әңгәмәдәләрнең бер-берсенең сөйләмен аңлавы. 2 нче сыйныфта ишетеп аңларга өйрәтүнең бурычлары түбәндәгеләр:
- нормаль темп белән әйтелгәннең ишетү аша мәгънәсен аңларга, аңлаган турында фикер йөртергә, аралашуда кулана белергә өйрәтү;
- сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләрне, грамматик формаларны бер-берсеннән ишетү аша аерырга өйрәтү;
- ишетү хәтеренең күләмен үстерү.
3.Уку
Сөйләм эшчәнлегенең бу төре буенча укучылар түбәндәге күнекмәләргә ия булырга тиешләр:
- хәреф-аваз системасын аера, татар теленә хас булган авазларны дөрес әйтеп укый белү;
- дәреслектә уку өчен бирелгән җөмләләрне, текстларны дөрес интонация белән укый белү;
- укыган материалның эчтәлегеннән кирәкле мәгълүматны аерып ала белү;
- кечкенә күләмле шигырьләрне яттан сөйләү;
- укыганда сүзлекләр куллана белү.
Дәреслектә уку техникасын үстерүгә ярдәм итә торган рифмовкалар, җырлар, рифмалаштырылган әкиятләр бирелде. Үзләштерү дәрәҗәсенә карап, укытучы аларны арттыра яки киметә ала.
4.Язу
Сөйләм эшчәнлегенең бу төре буенча укучылар түбендәге күнекмәләргә ия булырга тиешләр:
- татар алфавитындагы хәрефләрне дөрес, матур яза белү;
- дөрес күчереп язу күнекмәләрен булдыру;
бәйрәмнәр белән котлау язу

## II. Укыту предметының эчтәлеге

**Грамматик минимум**

1. Исемнәрнең килеш белән төрләнешен сөйләмдә куллануны камилләштерү.
2. Тартымлы исемнәрнең күплек санда төрләнеше белән таныштыру.
3. Кушма, парлы исемнәрнең мәгънәләрен аңлап, сөйләмдә куллану.
4. Чагыштыру, артыклык дәрәҗәсендәге сыйфатларның мәгънәләрен аңлап, сөйләмдә куллану.
5. Вакыт рәвешләре (бүген, иртәгә, кичә, иртән) белән таныштыру.
6. Монда, анда рәвешләрен сөйләмдә куллану.
7. Тамыр, кушма, тезмә саннар белән таныштыру.
8. Мин, син зат алмашлыкларының иялек, юнәлеш, урын-вакыт килешләрендә сөйләмдә кулланышы.
9. Кемдер, нәрсәдер алмашлыклары белән таныштыру.
10. Билгесез үткән заман хикәя фигыльне барлыкта 3 затта сөйләмдә куллану.
11. Ашыйсы килә, эчәсе килә формалары белән таныштыру.
12. Кебек бәйлеген сөйләмдә куллану.
13. Кадәр, соң – бәйлекләре белән таныштыру.
14. Ян бәйлек сүзен юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килешендәкуллану.
15. Уйнарга яратам, уйный башлады – төзелмәләребелән таныштыру.

**Орфоэпик һәм орфографик минимум.**

1. Сүз басымы. Аны дөрес куя белүгә ирешү, рус сүзләре белән чагыштырып күрсәтү. Басымлы иҗекләрне һәм сүзләрне дөрес уку һәм матур язу күнекмәләре булдыру.
2. Басымның үзенчәлекле очракларын белү.
3. Сингармонизм законының асылын гамәли үзләштерү.
4. Җөмлә ахырында нокта, сорау яки өндәү билгеләрен куеп, язу күнекмәләрен гомумиләштерү.

## III. Төп уку эшчәнлеге төрләре күрсәтелгән тематик планлаштыру

| № | Өйрәнелә торган бүлек, уку материалының темасы | Уку эшчәнлеге төрләре | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Планлаштырылган | Факт буенча |
| 1. | Яңа уку елы котлы булсын! | Тартым кушымчаларында к-г, б-п чиратлашуы. Аваз-хәреф мөнәсәбәтләре. Транскрипция билгеләре.Уку – язу әсбапларының дөрес язылышы. | 3.09 | |
| 2. | Уку – язу әсбаплары | -мы/- ме сорау кисәкчәләрен үзләштерү. Тиешле кушымчалар ялгап сорауларга җавап бирү. Җөмләахырынданокта, сорауякиөндәүбилгеләрен куеп, язу күнекмәләренгомумиләштерү. | 7.09 | |
| 3. | Уку – язу әсбаплары | Мин, синзаталмашлыкларының иялек, юнәлеш, урын-вакыткилешләрендәсөйләмдәкулланышы. | 10.09 | |
| 4. | Яңа уку елына әзерлек | Сан + исем конструкциясен дөрес куллану.Лексик берәмлекләрне дөрес язу күнекмәләрен ныгыту | 12.09 | |
| 5. | Яңа уку елына әзерлек<br>Кереш контроль эш. | Кереш контроль эш. Исемнәрнең тартым белән төрләнеше турында төшенчә бирү. Тартымлы исемнәрне сөйләмдә куллана белү | 17.09 | |
| 6. | Хаталар өстендә эш.<br>Х.Гардановның «К” хәрефен белегез, “К”ны дөрес әйтегез” шигырендәге лексик – грамматик материал.<br>Татар алфавиты. | Татар алфавитында сузык һәм тартык авазларның бирелеше. Хәреф-аваз системасына анализ ясый белү. Татар теленең үзенчәлекле авазларын аера белү (къ, гъ, җ, ң, һ, ч, һәмзә авазлары) | 21.09 | |
| 7. | Киң әйтелешле, тар әйтелешле о, ы, э авазлары | Алдагы сыйныфта үтелгән грамматик | 24.09 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | материалны искә төшерү.<br>Үтелгән кагыйдәләрне куллана белү О, ы, э хәрефләренең ике авазга билге булып йөрүе.<br>Алынма сүзләрнең сөйләмдә дөрес әйтелеше | | |
| 8. | 1-10 га кадәр һәм дистә саннары. | Сан һәм аның төркемчәләре турында төшенчә бирү.<br>Сан төркемчәләрен сөйләмдә дөрес куллану | 28.09 | |
| 9. | Б.Рәхмәтнең «Эш урыны»хикәясендәге лексик – грамматик материал | *Чөнки, шуңа* күрә теркәгечләрен кушма җөмләдә куллану | 1.10 | |
| 10. | Минем эш урыным | Вакыт берәмлекләре белән танышу.<br>Вакытны әйтә белү | 5.10 | |
| 11. | Кабатлау-йомгаклау дәресе | *Кичә, башта, аннан соң, озак* рәвешләрен язуда куллану.<br>Җөмләдә дөрес куллана белү | 8.10 | |
| 12. | **Туган як табигате.** | Грамматик кагыйдәләрне кабатлау. Үткән заман хикәя фигыльнең юклык формасын белдерү чараларын кабатлау | 12.10 | |
| 13. | Нәрсә ул табигать? | Кая? Кайда? Кайдан? сорауларының җөмләдә кулланылышы.<br>Тиешле кушымчалар ялгап сорауларга җавап бирү | 15.10 | |
| 14. | Көзге табигать.<br>Контроль эш | Төшем килешендәге исемнәрне сөйләмдә ныгыту. Кемне? Нәрсәне? сорауларын үзләштерү. | 19.10 | |
| 15. | Хаталар өстендә эш. Һава торышы | Кушма, парлыисемнәрнеңмәгънәләренаңлап, сөйләмдәкуллану.<br>Төшем килеше соравын кулланып җөмләләр төзи белү | 22.10 | |
| 16. | Кошлар безнең дусларыбыз. | . Чөнки, шуңа күрә теркәгечләре | 26.10 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 17. | Г.Лотфиның “Песнәк белән Әнисә” хикәясендәге лексик – грамматик материал | Яңа сүзләрне куллану | 29.10 | |
| 18 | Канатлы дуслар. Алар нидиләр? | Йорт, кыргый хайваннарның исемнәрен атый, аларны сурәтли белү. | 9.11 | |
| 19. | Йорт һәм кыргый хайваннар | Керпе турында сөйли белү. Диалогны сәхнәләштерү. | 12.11 | |
| 20 | Тиен турында сөйләшү | Хикәя төзү күнекмәләрен камилләштерү. Сүз тәртибен дөрес кулланып җөмләләр төзеп сөйләү. | 16.11 | |
| 21 | Без табигатьне саклыйбыз. | Кышкы табигатне сөйли белү | 19.11 | |
| 22 | Йорт һәм кыргый хайваннарны кабатлау | “Кышкы уеннар” темасы буенча ситуатив күнегүләр эшләү. Актив үзләштерелгән лексик берәмлекләрне камилләштерү | 23.11 | |
| 23 | Кыш билгеләре | Яңа ел бәйрәме турында сөйләшү | 26.11 | |
| 24 | Кыш билгеләре Һава торышын | Кай төшең авыртканын әйтә белү.Нәрсә кигәнеңне әйтә белү. | 30.11 | |
| 25 | Г. Бакирның “Кышкы уеннар” хикәясендәге лексик – грамматик материал | Кая? Кайда?, Кайдан? Сорауларына җавап бирү | 3.12 | |
| 26 | Кар бабай ясыйбыз. | Образларга бәя бирә белү. Бергә уйнау турында сөйләшү. | 7.12 | |
| 27 | Яңа ел бәйрәме | Уенга, шугалакка чакыра белү. | 10.12 | |
| 28 | “Кышкы уеннар” темасын кабатлау. | Гомумиләштереп кабатлау | 14.12 | |
| 29 | “Минем дустым” темасына сөйләшү. Контроль эш | Диалоглар төзү, төшеп калган репликалар кую | 17.12 | |
| 30 | Дуслар белән күңелле<br>.<br>Хаталар өстендә эш | Тартымлы исемнәрнең күплек санда төрләнеше белән таныштыру.Тартым кушымчаларын дөрес куллана белү | 21.12 | |
| 31 | . Дуслар белән күңелле | Белемнәрне тикшерү | 24.12 | |
| 32 | Г. Бәшировның “Сылтау хикәясендәге лексик – грамматик материал . хикәясе | Тартымлы исемнәрнең күплек санда төрләнеше белән | 11.01 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Чын дусмы? | таныштыру.Тартым кушымчаларын дөрес куллана белү | | |
| 33 | Әти-әниләрнең прфессиясе | Әти-әниләрнең прфессиясе | 14.01 | |
| 34 | Әти-әниләрнең прфессиясе | Сүз ясагыч - *чы/ -че* кушымчасын үзләштерү | 18..01 | |
| 35 | И. Туктарның “Алма” хикәясендәге лексик – грамматик материал . | Орфографик, грамматик дөрес язу күнекмәләрен һәм бәйләнешле сөйләм телен үстерү | **21.01** | |
| 36 | И. Туктарның “Алма” хикәясендәге .Без хикәя язабыз | Сорау алмашлыклары булган җөмләләрне дөрес тәрҗемә итү | 25.01 | |
| 37 | “Минем дусларым” темасы буенча<br>Кабатлау-йомгаклау дәресе | “Минем дусларым” темасы буенча ситуатив күнегүләр эшләү. Өйрәнелгән яңа лексиканы активлаштыру | 28.01 | |
| 38 | Минем дүрт аяклы дустым бар | Үтелгән грамматик берәмлекләрне активлаштыру<br>Язуда актив куллану | 1.02 | |
| 39 | Р Мингалимнең “Дөньяда бер эт бар иде” шигырендәге лексик, грамматик материал | Теркәгечләр белән җөмләләр төзү | 4.02 | |
| *40* | Р Мингалимнең “Дөньяда бер эт бар иде” .Малай нинди ялгышлык эшләде. | Шигырьнең эчтәлеге буенча хикәя язу<br>Өйрәнгән грамматик структураларны дөрес куллану | 8.02 | |
| *41* | Г. Мөхәмәтшин.<br>“Ак песи” хикәясендәге лексик, грамматик материал | Теләк белдерү формаларын үзләштерү | 11.2 | |
| *42* | Г. Мөхәмәтшин.<br>“Ак песи” хикәясендәге лексик, грамматик материал | –сыз/ -сез аффиксларын үзләштерү.<br>–сыз/ -сез аффикслы сүзләрне дөрес тәрҗемә итү | 15.2 | |
| 43 | *Яз билгеләре.* | Лексик –грамматик материалны ныгыту.Җөмләдә дөрес куллана белү | 18.02 | |
| 44 | Яз билгеләре | *Буе* бәйлек сүзен җөмлә төзүдә куллана белү | 21.02 | |
| 45 | Лев Толстойның “Әби белән онык” хикәясендәге лексик, грамматик материал. | . Сүз тәртибен дөрес кулланып җөмләләр төзү | 22.02 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 46 | Лев Толстойның “Әби белән онык” хикәясе.Мин өйдә булышам | Өй хезмәте турында сөйли, сөйләшә белү. Билгесез үткән заман хикәя фигыльне сөйләмдә куллана белү | 25.02 | |
| 47 | Әниләр бәйрәме | Үрнәк буенча эшләү.8 нче март бәйрәме белән котлау язу. Котлау язу күнекмәләрен мөстәкыйль куллана белү | 1.03 | |
| 48 | **Язгы бәйрәмнәр”темасы буенча кабатлау.** | Алган белемнәрне мөстәкыйль куллана белү | 4.03 | |
| 49 | **Контроль эш. Язгы бәйрәмнәр”темасы буенча** | Белемнщрне тикшерү | 8.03 | |
| 50 | Хаталар өстендә эш.<br>В. Осееваның “Дүрт кыз” хикәясе | Билгесез үткән заман фигыль кушымчаларын җөмләдә дөрес куллана белү | 11.03 | |
| *51* | В. Осееваның “Дүрт кыз” хикәясе .Ничек әдәпле сорарга? | Үтенечне белдерү формаларын үзләштерү | 15.03 | |
| *52* | Ярдәм сорыйбыз | Үтенечне белдерү формаларын үзләштерү | 18.03 | |
| *53* | “Язгы бәйрәмнәр”темасы буенча кабатлау йомгаклау дәресе | “Яз килә”темасына ситуатив күнегүләр эшләү. Өйрәнелгән лексик, грамматик материалның үзләштерелү дәрәҗәсен тикшерү | 22.03 | |
| *54* | Минем Ватаным –Россия. | Алган белемнәрне мөстәкыйль куллана белү | 1.04 | |
| *55* | Татарстанның дәүләт символлары | | 5.04 | |
| *56* | Казан –Татарстанның башкаласы | Ялгызлык исемнәрнең язылышын истә калдыру | 8.04 | |
| *57* | Казан –Татарстанның башкаласы | | 12.04 | |
| *58* | “Татарстан шәһәрләре | Алган белемнәрне мөстәкыйль куллана белү | 5.04 | |
| *59* | Татарстан шәһәрләре | | 19.04 | |
| *60* | Кабатлау-йомгаклау дәресе | Актив үзләштерелгән лексик берәмлекләрне дөрес язу, сөйләмдә куллану күнекмәләрен ныгыту | 22.04 | |
| *61* | Ш. Галиев. | Яңа лексик берәмлекләр | 26.04 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | “Җәйге болында” шигырендәге лексик – грамматик материал. | үзләштерү | | |
| *62* | Җәйге табигать | 1-4 сыйныфларда өйрәнгән лексик-грамматик материалның үзләштерелү дәрәҗәсен тикшерү | 29.04 | |
| *63* | Җиләктә | Өйр5әнгән грамматик структураларны дөрес куллану | 3.0 5 | |
| *64* | “Шүрәле” әкиятендәге лексик – грамматик материал. | Актив үзләштерелгән лексик берәмлекләрне дөрес язу, сөйләмдә куллану күнекмәләрен ныгыту | 6.05 | |
| *65* | **Еллык йомгаклау контроль эше** | Өйрәнелгән лексик, грамматик материалның үзләштерелү дәрәҗәсен тикшерү | 10.05 | |
| *66* | Хаталар өстендәә эш. Җәйге ял | “Минем туган илем” темасына ситуатив күнегүләр эшләү. | 13.05 | |
| *67* | Җәйге ял. | “Чәчәкле җәй, ямьле җәй” темасына ситуатив күнегүләр эшләү. Өйрәнелгән лексик, грамматик материалның үзләштерелү дәрәҗәсен тикшерү | **17.05** | |
| *68* | Ел буена үткәннәрне кабатлау | Чәчәкле җәй, ямьле җәй” темасына ситуатив күнегүләр эшләү. Өйрәнелгән лексик, грамматик материалның үзләштерелү дәрәҗәсен тикшерү | **20.05** | |
| *69* | Ел буена үткәннәрне кабатлау | Өйрәнелгән лексик, грамматик материалның үзләштерелү дәрәҗәсен тикшерү | **24.05** | |
| *70* | Ел буена үткәннәрне кабатлау. Өомгаклау дәрес | Өйрәнелгән лексик, грамматик материалның үзләштерелү дәрәҗәсен кабатлау | **30.05** | |